| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от 08.12.2014** **№ 391**

**Товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) куллануның дөреслеген һәм аларның күләмнәренең дәлиллеген контрольдә тоту буенча чаралар үткәргәндә, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты билгеләгән гражданнарны аттестацияләү Комиссиясе турында Нигезләмәне һәм товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) куллануның дөреслеген һәм аларның күләмнәренең дәлиллеген контрольдә тоту өлкәсендә экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару Кагыйдәләрен раслау турында**

«Дәүләт контролен (күзәтүен) һәм муниципаль контрольне үтәгәндә юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрь № 294-ФЗ Федераль законы нигезендә һәм «Органнар тарафыннан дәүләт контролен (күзәтүен), муниципаль контрольне, контроль буенча чараларны үткәрүгә билгеләнгән экспертларны аттестацияләү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 10 июле №636 карарын үтәү максатыннан чыгып,

боерам:

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан товарларга ( эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) куллануның дөреслеген һәм аларның күләмнәренең дәлиллеген контрольдә тоту буенча чаралар үткәрүгә эксперт сыйфатында билгеләнгән гражданнарны

аттестацияләү Комиссиясе Нигезләмәсен (алга таба – Нигезләмә), шушы боерыкның 1 кушымтасы белән килештереп.

1.2. Товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен  (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) куллануның дөреслеген һәм аларның күләмнәренең дәлиллеген котрольдә тоту өлкәсендә экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару Кагыйдәләрен, шушы боерыкның 2 кушымтасы белән килештереп.

2. Шушы боерык рәсми басылып чыккач, ун көннән соң, үз көченә керә.

3. Шушы боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитеты боерыгына
1 кушымта
_________________ № _______

**Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) куллануның дөреслеген һәм аларның күләмнәренең дәлиллеген контрольдә тоту буенча чаралар үткәрүгә эксперт сыйфатында билгеләнгән гражданнарны аттестацияләү Комиссиясе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) куллануның дөреслеген һәм аларның күләмнәренең дәлиллеген контрольдә тоту буенча чаралар үткәрүгә Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан эксперт сыйфатында билгеләнгән гражданнарны аттестацияләү Комиссиясе (алга таба – Комиссия) аттестациягә белдерелгән эшчәнлекләр өлкәсендә: электр энергетикасында, газ белән тәэмин итүдә, җылылык белән тәэмин итүдә, су белән тәэмин итүдә, субүлүдә, каты көнкүреш калдыкларын урнаштыруда, транспорт хезмәтләрендә көйләүле бәяләрнең (тарифларның, өстәмә түләүләрнең, арттырылган бәяләрнең) күләмнәренең дәлиллегенә һәм аларның дөрес кулланылышына экспертиза үткәрүгә билгеләнгән экспертларны аттестацияләү өчен төзелә.

1.2. Нигезләмә Комиссиянең составын һәм эш тәртибен билгели.

1.3. Комиссия үзенең эшчәнлегендә федераль законнарга, «Органнар тарафыннан дәүләт контролен (күзәтүен), муниципаль контрольне, контроль буенча чараларны үткәрүгә билгеләнгән экспертларны аттестацияләү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 10 июле №636 карарына, шушы Нигезләмәгә таянып, эш итә.

## 2. Комиссияне формалаштыру һәм эш тәртибе

2.1. Комиссия составы Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

2.2. Комиссия рәистән, аның урынбасарыннан, сәркатибеннән һәм Комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлеге белән идарә итә, Комиссия утырышының датасын һәм көн тәртибен раслый, Комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларны имзалый.

Комиссия рәисе урында булмаган очракта, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.4. Комиссия сәркатибе Комиссия эшен тәэмин итә, шул исәптән Комиссия әгъзаларына утырышлар датасын һәм вакытын хәбәр итә, Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча рәсми эш кәгазьләрен тутыра, материалларны саклауны һәм алга таба аларны архивка тапшыруны тәэмин итә, Комиссиянең эш тәртибе һәм аттестация мәсьәләләре буенча гражданнарга киңәшләр бирә.

2.5. Комиссия эшчәнлегенең төп формасы булып утырышлар тора, аларда квалификацияне билгеләүче имтиханнар үткәрелә.

2.6. Квалификацияне билгеләүче имтихан дәгъвачының экспертлыкка квалификациясен тикшерү максатыннан үткәрелә. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча Комиссия аттестация критерийлары нигезендә экспертлыкка дәгъвачының вазифаларга туры килүе яки туры килмәве турында карар кабул итә.

2.7. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән, Комиссия әгъзалары утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының яртысыннан азрак кеше катнашмаса, ул үз компетенциясендә каралган мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

2.8. Комиссия карары шушы Нигезләмәнең 1 кушымтасындагы форма белән килештереп, беркетмә белән тутырыла. Комиссия беркетмәсен Комиссия сәркатибе тутыра, аны Комиссия рәисе һәм Комиссия әгъзалары Комиссия утырышы көнендә имзалыйлар.

2.9. Комиссия квалификация имтиханын, Дәүләт комитетына экспертлыкка аттестация үтүгә дәгъва белдерүче гражданнан аттестация турында гариза алынган көннән башлап, 3 айдан да соңармыйча үткәрә.

## 3. Квалификация имтиханын үткәрү тәртибе

3.1. Эксперт аттестациясен үтүгә дәгъва белдергән граждан, Дәүләт комитетына мондый документлар тапшыра:

- аттестация үтү турында шушы Нигезләмәнең 2 кушымтасындагы форма белән килештерелгән гариза;
- белемне раслаучы документлар күчермәләре, шулай ук (булган очракта) гыйльми дәрәҗәне раслаучы документлар күчермәләре, аттестатлар, сертификатлар, таныклыклар күчермәләре;
- экспертизаның гаризада белдерелгән төренә туры килгән белгечлек буенча эшчәнлекне раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе;
- аттестация үтүгә белдерелгән эшчәнлек өлкәсендә экспертизаларда катнашуны раслаучы һәм дәгъвачының эксперт эшчәнлеген үтәргә сәләтен бәяләргә мөмкинлек биргән документлар (булган очракта) күчермәләре.

Экспертлыкка аттестация үтүгә дәгъва белдергән граждан аттестация үтү турында гаризаны һәм аңа беркетелгән документларның күчермәләрен Дәүләт комитетына шәхсән үзе тапшыра яки почта аша заказ белән тапшыру турында

аныклык кертеп яки «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша гади электрон имза белән электрон документ рәвешендә җибәрә.

3.2. Квалификация имтиханына Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән һәм Нигезләмәнең 5.1.1, 5.1.2 пунктларында каралган аттестация критерийларына туры килгән барлык тиешле документларны тапшырган гражданнар үткәрелә.

3.3. Квалификация имтиханын үткәргәндә Комиссия:

- экспертлыкка дәгъвачы тапшырган документлар белән таныша;

- экспертлыкка дәгъвачының эксперт эшләрен үткәрүгә кирәк булган тиешле теоретик һәм практик әзерлеген, тәҗрибәсен, компетентлылыгын бәяли.

3.4. Квалификация имтиханы Нигезләмәнең 5 бүлекчәсендә каралган экспертлыкка дәгъвачының аттестация критерийларына туры килүен билгеләү максатында, әңгәмә формасында үткәрелә.

3.5. Квалификация имтиханы нәтиҗәсендә Комиссия экспертлыкка дәгъвачының, Нигезләмәнең 5 бүлекчәсендә каралган аттестация критерийларына туры килүе яки туры килмәве турында дәлилле карар чыгара.

3.6. Квалификация имтиханының нәтиҗәсе Комиссия беркетмәсе белән раслана, аның нигезендә әгәр экспертлыкка дәгъвачының аттестация критерийларына туры килүе яки аттестация үтмәве турында карар кабул ителсә, әгәр экспертлыкка дәгъвачының аттестация критерийларына туры килмәве яки квалификаия имтиханына килмәве турында карар кабул ителсә, Комиссия сәркатибе экспертлыкка кандидатның аттестацияләнүе яки яки аттестация үтүдән читләштерелүе турында Дәүләт комитетының боерыгы проектын әзерли.

Дәүләт комитетының боерыгы күчермәсе  карар чыгарганнан соң, 3 эш көне эчендә гариза бирүчегә тапшырыла, яки почта аша заказ белән тапшыру турында аныклык кертеп яки «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша  гади электрон имза белән электрон документ рәвешендә җибәрелә.

## 5. Экспертларны аттестацияләү критерийлары

5.1. Эксперт статусын алуга дәгъва белдергән, Дәүләт комитеты тарафыннан товарларга ( эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) кулланунын дөреслеген һәм аларның күләмнәренең дәлиллеген контрольдә тоту буенча чаралар үткәрүгә эксперт сыйфатында билгеләнгән гражданнар мондый таләпләргә туры килергә тиешләр:

5.1.1. Экспертлыкка дәгъвачы  шәхси эшмәкәр, аттестация үтүгә белдерелгән эшчәнлек өлкәсендә эшләүче предприятиенең учредителе, директоры, вазифалар башкаручы заты булырга тиеш түгел.

5.1.2. Экспертлыкка дәгъвачының булырга тиеш:

а) югары икътисади һәм ( яки) техник белеме (аттестация үтүгә белдерелгән эшчәнлек өлкәсендә);

б) аттестация үтүгә белдерелгән эшчәнлек өлкәсендә эш стажы кимендә 5 ел.

5.1.3. Экспертлыкка кандидат белергә тиеш:

а) аттестация үтүгә белдерелгән эшчәнлек өлкәсендәге законнарны;

б) бухгалтерлык һәм салым хисабы өлкәсендәге законнарны;

в) аттестация үтүгә белдерелгән эшчәнлек өлкәсендә бәяләр билгеләү нигезләрен;

г) оешма эшчәнлегенең финанс-хуҗалык анализы нигезләрен.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган Нигезләмәнең 1 кушымтасы
_________________ № _______

Беркетмә № _________

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының экспертлар сыйфатында контроль буенча чараларны үткәргәндә билгеләнүче гражданнарны аттестацияләү Комиссиясе утырышы

_______________
(дата)

Комиссия составында:
Комиссия рәисе: ______________________
Комиссия рәисе урынбасары: ______________________
Комиссия әгъзалары: ______________________

товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) куллануның дөреслеген һәм аларның күләмнәренең дәлиллеген контрольдә тоту буенча чаралар үткәрүгә Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты экспертлыкка дәгъвачылар арасында квалификация имтиханы үткәрде:

| № т/б | Дәгъвачының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Экспертиза төре (аттестация үтүгә белдерелгән эшчәнлек өлкәсен күрсәтеп) | Имтихан нәтиҗәсе (аттестация критерийларына туры килә/туры килми) |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Комиссия рәисе_________________________________
(имза) (имза тулысынча)
Комиссия рәисе урынбасары_________________________________
(имза) (имза тулысынча)
Комиссия сәркатибе_________________________________
(имза) (имза тулысынча)
Комиссия әгъзалары_________________________________
(имза) (имза тулысынча)

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты боерыгы белән
расланган Нигезләмәнең 2 кушымтасы
__________________ № ________

Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисенә
_____________________________________
______________________________________
________________________________
(Гариза бирүченең ФИА, туу датасы)
______________________________________
(ИНН)
______________________________________
(шәхесне раслаучы документ мәгълүматлары)
______________________________________
(яшәү урыны адресы)
______________________________________
(телефон номеры)
______________________________________
( электрон почта адресы)

Экспертны аттестацияләү турында гариза

Товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) куллануның дөреслеген  һәм аларның күләмнәренең дәлиллеген контрольдә тоту буенча Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты чаралар үткәргәндә, ________________ өлкәсендә бәяләрнең (тарифларның, өстәмә түләүләрнең, арттырылган бәяләрнең) күләмнәренең дәлиллегенә һәм аларны куллануның дөреслегенә экспертиза үткәрүгә билгеләнү өчен, эксперт сыйфатында аттестацияләвегезне үтенәм.

Кушымталар:

- белемне раслаучы документлар күчермәләре, шулай ук (булган очракта) гыйльми дәрәҗәне раслаучы документлар күчермәләре, аттестатлар, сертификатлар, таныклыклар күчермәләре;

- экспертизаның билдерелгән төренә туры килгән белгечлек буенча эшләгәнне раслаган хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

- билдерелгән эшчәнлек өлкәсендә экспертизалар үткәрүдә катнашуны раслаучы һәм дәгъвачының эксперт эшчәнлегенә сәләтен бәяләргә мөмкинлек биргән документлар (әгәр булса) күчермәләре.

_____________________________________ (дата)

___________________________ (гариза бирүченең имзасы)

Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитеты боерыгына
2 кушымта
_________________ № _______

**Товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) куллануның дөреслеген һәм аларның күләмнәренең дәлиллеген контрольдә тоту өлкәсендә экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару Кагыйдәләре**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Шушы Кагыйдәләр Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан (алга таба – Дәүләт комитеты) товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләтнең тиешле көйләүле бәяләрен (тарифларны, өстәмә түләүләрне, арттырылган бәяләрне) куллануның дөреслеген һәм аларның күләмнәренең (алга таба - Реестр) дәлиллеген контрольдә тоту буенча чаралар үткәрүгә билгеләнгән экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару, шул исәптән Реестрга кертелгән мәгълүматлар составын һәм Реестрдан мәгълүматлар бирү тәртибен билгели.

1.2. Реестрны формалаштыруны һәм алып баруны Дәүләт комитетының административ практика бүлеге электрон формада гамәлгә ашыра.

2. Экспертлар Реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе

2.1. Реестрга экспертлар турында мәгълүматларны кертүгә нигез булып Дәүләт комитетының экспертларны аттестацияләү хакында, шулай ук аттестация вакытының туктатылуы хакында карары тора.

2.2. Реестр мондый мәгълүматларны үз эченә ала:

а) язманың теркәү номеры;

б) Реестрга эксперт турында мәгълүматлар кертү датасы;

в) физик затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), аның яшәү урыны адресы, шәхесен раслаучы документ мәгълүматлары, телефон номеры һәм электрон почта адресы (булган очракта), салым түләүченең идентификацияләнгән номеры;

г) эшчәнлек өлкәсе күрсәтелгән экспертиза төре;

д) аттестацияләнү турындагы номер һәм карар чыгарылган дата;

е) кабат аттестация үтү турында мәгълүматлар;

ж) аттестация вакыты тәмамлану датасы;

з) экспертның аттестация вакыты туктатылу турында чыгарылган карар номеры һәм датасы;

и) эксперт эшли торган яки ул хезмәтләр күрсәтү максатында эшчәнлек алып бара торган оешманың исеме һәм урыны.

2.2. Дәүләт комитеты Реестрга мәгълүматларны кертүне, 3 эш көненнән дә

соңга калмыйча тәэмин итә:

а) аттестация турында, аттестация вакыты туктатылу турында карарлар кабул итү;

б) Реестрга кертелгән мәгълүматлардагы үзгәрешләр турында белешмә кертү.

3. Реестрдагы мәгълүматларны тапшыру тәртибе

3.1. Реестрда тупланган мәгълүматлар, Россия Федерациясе законнарынигезендә чикләүләр кертелгән мәгълүматлардан тыш, алар белән танышу өчендәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары , юридик, физик затлар өчен ачык булып тора.

3.2. Реестрда тупланган мәгълүматларга үтеп керү “Интернет” мәгълүмат – телекоммуникацияләр челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында мәгълүматларны ачык рәвештә урнаштыру юлы белән тәэмин ителә.